ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

22.11.2018 с. Верхний Услон 1363

«Җәмәгать тәртибен саклауда актив
катнашкан өчен» премиясе турында

«Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуы турында» 2015 елның 16 гыйнварындагы 4 - ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Югары Ослан муниципаль районы территориясендә җәмәгать тәртибен саклауны гамәлгә ашыруда катнашучы халык дружиналары әгъзаларын бүләкләү максатларында Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының «Җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен» премиясе турындагы нигезләмәне расларга (1 нче Кушымта).

2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының «Җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен» премиясен бирү өчен кандидатураларны карау комиссиясе составын расларга (2 нче Кушымта).

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль-мәдәни мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Л.С. Хакимзянов**

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының 22.11.2018 №1363 карарына

1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының «Җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен» премиясе турында**

# НИГЕЗЛӘМӘ

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының «Җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен премиясе» (алга таба – премия) ел саен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы җәмәгать тәртибен саклауны тормышка ашыруда катнашучы халык дружиналары (алга таба-ХД) әгъзаларын бүләкләү максатында бирелә.

2. Премия ел йомгаклары буенча елга бер тапкыр бирелә. Премия 3,0 мең сум күләмендә бирелә.

3. Премия бирү өчен Татарстан Республикасында халык дружиналары һәм хокук саклау юнәлешендәге иҗтимагый берләшмәләр реестрына кертелгән НД әгъзалары кандидатлар булырга мөмкин.

4. Халык дружиналары координацияләүче орган (штаб) җитәкчесе һәм эчке эшләр органы (полиция) җитәкчесе кул куйган премия бирү өчен кандидатны тәкъдим итү Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районында ел тәмамланырга 10 көн кала (20 декабрьгә кадәр) халык дружиналары эшчәнлеген координацияләү буенча район штабына җибәрелә.

5. Кандидатны премия бирү өчен тәкъдим итү формасы Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының «Җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен» премиясен бирү кандидатураларын карау комиссиясе (алга таба – Комиссия) тарафыннан раслана.

6. Әлеге Нигезләмәнең 5 пунктында күрсәтелгән кабул итү вакытын бозып тәкъдим ителгән һәм (яисә) билгеләнгән үрнәккә җавап бирми торган премия бирү өчен кандидатка тәкъдим итү карауга кабул ителми.

7. Комиссия үз утырышында кандидатлар тәкъдим итүне карый.

8. Комиссия үз утырышларына хокук саклау органнары, дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, җирле үзидарә органнары вәкилләрен һәм халык дружиналары командирларын чакырырга хокуклы.

9. Премия бирү турындагы карар комиссия утырышында катнашучыларның күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышларның тигезлеге очрагында утырышта рәислек итүче тавышы хәлиткеч булып тора.

10. Карар кабул иткәндә түбәндәге критерийлар исәпкә алына:

- массакүләм чаралар үткәргәндә НД әгъзасы катнашуы;
- даими рәвештә дежурлыкка чыгу;
- административ хокук бозуларны ачыклау һәм булдырмау;
- җинаятьләрне ачуда хокук саклау органнарына ярдәм күрсәтү.

11. Комиссия карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул өч көн эчендә тавыш бирүдә катнашкан комиссия рәисе һәм барлык әгъзалары тарафыннан имзалана.

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының 22.11.2018 № 1363 карарына

2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының «Җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен» премиясен бирү кандидатураларын карау комиссиясе составы**

**Рәис:**

| | | |
|---|---|---|
| Хакимзянов Ленар Саетзянович | – | Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе |

**Сәркатип:**

| | | |
|---|---|---|
| Митяшкина Татьяна Олеговна | – | Югары Ослан муниципаль районы Советының исәп һәм хисап бүлеге баш белгече (килешү буенча) |

**Әгъзалар:**

| | | |
|---|---|---|
| Камалетдинова Гулия Фидаиловна | – | Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль-мәдәни мәсьәләләр буенча урынбасары |
| Арефьев Дмитрий Алексеевич | – | РФ ЭЭМ «Югары Ослан» муниципальара бүлеге башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| Колесова Елена Евгеньевна | – | Югары Ослан муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе (килешү буенча) |